КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 декабрь г.Казань № 1081

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 938 нче карары белән расланган Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 938 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 февраль, 168 нче; 2022 ел, 17 июнь, 583 нче; 2023 ел, 4 июль, 785 нче; 2023 ел, 2 ноябрь, 1403 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле

эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның 2 пунктчасында «бүлекнең әйдәүче консультанты,» сүзләреннән соң «1 категорияле өлкән белгеч,» сүзләрен өстәргә;

4.3 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.5 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) консультация бирү әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән инспекторлар тарафыннан телефон аша, видео-конференц-элемтә ярдәмендә, шәхси кабул иткәндә яисә профилактик чара, контроль (күзәтү) чарасы үткәрү барышында гамәлгә ашырыла.

Контрольдә тотылучы зат консультациягә язылырга, шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы) аша язылырга мөмкин.

Шәхси мөрәҗәгать иткәндә консультация вакыты контрольдә тотучы орган җитәкчесе тарафыннан билгеләнә, ул кимендә 15 минут тәшкил итәргә һәм контрольдә тотучы органның гражданнар өчен ачык урында урнашкан стендында, контрольдә тотучы органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтында күрсәтелергә тиеш.

Төбәк дәүләт контролен (күзәтүен) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча консультация алырга теләгән контрольдә тотылучы затларга аннан файдалану хокукы чират тәртибендә бирелә.

Гражданнар шәхси мөрәҗәгать иткәндә чиратта көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Консультация бирүче инспектор гражданнарның ризалыгы белән һәр бирелгән сорау буенча телдән җавап яки аларга кайда һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге турында телдән аңлатма бирә.

Консультациянең эчтәлеге консультациянең исәпкә алу карточкасына кертелә, аның бертип формасы контрольдә тотучы орган тарафыннан раслана.

Консультацияләр карточкаларын исәпкә алу консультацияләр карточкалары журналын алып бару юлы белән гамәлгә ашырыла, аның бертип формасы контрольдә тотучы орган тарафыннан раслана.

Консультация нәтиҗәләре буенча мәгълүмат контрольдә тотылучы затларга һәм аларның вәкилләренә язма формада бирелми. Контрольдә тотылучы зат язмача җавап бирү турында рәсми сорауны «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән сроклар эчендә җибәрергә хокуклы.

Контрольдә тотучы органга мөрәҗәгать иткән гражданнардан консультациягә шәхси кабул ителү барышында төбәк дәүләт контролен (күзәтүен) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча язма мөрәҗәгатьләр алынырга мөмкин, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлергә һәм карап тикшерелергә тиеш.

Консультация биргәндә инспектор файдалану мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш.

Консультация барышында билгеле бер контроль (күзәтү) чарасын, контрольдә тотучы орган инспекторлары, контроль (күзәтү) чарасында башка катнашучылар карарларын һәм (яки) гамәлләрен бәяләүдән гыйбарәт мәгълүмат бирелә алмый;»;

4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Профилактик визит 248-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Профилактик визит контрольдә тотылучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан яисә видео-конференция-элемтәне яки «Инспектор» мобиль кушымтасын куллану юлы белән профилактик әңгәмә рәвешендә уздырыла.

Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы затка аның эшчәнлегенә яисә аның карамагындагы контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның риск критерийларына туры килүе турында, риск категориясен киметү буенча тәкъдим ителә торган ысуллар турында, тиешле риск категориясенә кертелүенә карап, контроль объектына карата үткәрелә торган контроль (күзәтү) чаралары төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында мәгълүмат бирелә, ә инспектор контроль объекты белән таныша, контроль объектларын риск категорияләренә кертү өчен кирәкле мәгълүмат җыя һәм контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлү дәрәҗәсен бәяли.

Профилактик визит контроль (күзәтү) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яки контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча үткәрелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.7 пункт өстәргә:

«4.7. Мәҗбүри профилактик визит 248-ФЗ номерлы Федераль законның $52^1$ статьясы нигезендә башкарыла.

Мәҗбүри профилактик визит Россия Федерациясе Президенты; Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе яки Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе – Россия Федерациясе Хөкүмәте Аппараты Җитәкчесе Урынбасары белән килештерелгән Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары; Татарстан Республикасы Рәисе кушуы буенча үткәрелә.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү срогы 10 эш көненнән артып китә алмый һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.8 пункт өстәргә:

«4.8. Контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча профилактик визит 248-ФЗ номерлы Федераль законның $52^2$ статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Профилактик визит контрольдә тотылучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан яисә видео-конференция-элемтәне яки «Инспектор» мобиль кушымтасын куллану юлы белән профилактик әңгәмә рәвешендә уздырыла.»;

5.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) контрольдә тотучы органда, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, закон белән сакланыла торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү яки зыян (зарар) китерү куркынычы янау турында белешмәләр булу;»;

түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен яки контроль объектының шундый параметрлардан тайпылуын ачыклау;»;

түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) контрольдә тотылучы затның мәҗбүри профилактик визит уздырудан читләшүе.»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планнан тыш документларны тикшерү бары прокуратура органнары белән килештереп (248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә аны үткәрү очрагыннан тыш) башкарылырга мөмкин.»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган нигез буенча контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлек карала торган контроль (күзәтү) чарасын үткәрү турында контрольдә тотучы орган карары түбәндәгеләр турында дөрес мәгълүмат булганда кабул ителә:

1) гражданнарның тормышына зыян китерү яки сәламәтлегенә авыр яки уртача зыян (зарар) китерү куркынычы турыдан-туры янау турында;

2) ил оборонасына һәм дәүләт иминлегенә зыян (зыян) китерү яки зыян (зарар) китерү куркынычы турыдан-туры янау турында.»;

5.8 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документар тикшерүне үткәрү срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш. Контрольдә тотучы орган тарафыннан контрольдә тотылучы затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны кертү таләбе алынган вакыттан контрольдә тотучы органга таләптә күрсәтелгән документлар тапшырылган вакытка кадәр, шулай ук контрольдә тотучы орган тарафыннан контрольдә тотылучы затка тапшырылган документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында яисә бу документлардагы белешмәләрнең контрольдә тотучы орган документларындагы һәм (яки) дәүләт контролен (күзәтүен), муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында мәгълүмат һәм кирәкле язма аңлатмаларны бирү таләпләре җибәрелгән вакыттан кирәкле язма аңлатмалар контрольдә тотучы органга бирелгәнгә кадәр документар тикшерүне үткәрү срогын исәпләү туктатып торыла.»;

5.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Контрольдә тотучы орган, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләр кергәндә һәм мәҗбүри таләпләр бозуларны булдырмау һәм бетерү буенча кичектергесез чаралар күрергә кирәк булган очракта, планнан тыш контроль (күзәтү) чарасын кичекмәстән (әлеге белешмәләр кергәннән соң 24 сәгать эчендә) уздыруга карешә, бу хакта контроль объекты урнашкан урын буенча прокуратура органына, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 5 өлешендә каралган документларны шул ук срок эчендә җибәреп, хәбәр итә. Бу очракта контрольдә тотылучы затка планнан тыш контроль (күзәтү) чарасын үткәрү турында хәбәр ителмәскә мөмкин.»;

5.11 пунктта:

беренче абзацта «дәүләт контроль органына» сүзләрен «контрольдә тотучы органга» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «дәүләт контроль органы» сүзләрен «контрольдә тотучы орган» сүзләренә алмаштырырга;

5.12 пунктта:

өченче абзацта «контроль (күзәтү) органы» сүзләрен «контрольдә тотучы орган» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «хисап» сүзен «акт» сүзенә алмаштырырга;

6.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әгәр мондый чара үткәрү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланса, актта нинди мәҗбүри таләпнең бозылуы, нинди норматив хокукый акт һәм аның структур берәмлеге белән билгеләнүе күрсәтелергә тиеш. Ачыкланган бозу контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль (күзәтү) чарасын үткәрү тәмамланганга кадәр бетерелгән очракта, актта аны бетерү факты күрсәтелә. Мәҗбүри таләпләрне бозуны дәлилли торган документлар, башка материаллар актка теркәлергә тиеш.

Акт мондый чара үткәрү тәмамланган көнне контроль (күзәтү) чарасын үткәрү урынында яисә, әгәр мондый чара үткәрү урынында акт төзү 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән сәбәпләр аркасында мөмкин булмаса, әгәр актны рәсмиләштерү өчен башка тәртип 248-ФЗ номерлы Федераль законда яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чара үткәрү тәмамланган көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелә.

Контрольдә тотылучы зат яки аның вәкиле, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 88 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, контроль (күзәтү) чарасы үткәрү урынында акт эчтәлеге белән таныша.

«Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып, контроль (күзәтү) чаралары үткәрелгән яисә контроль (күзәтү) чарасы акты үзара хезмәттәшлек итмичә төзелгән очракта, шулай ук контроль (күзәтү) чарасы үткәрү урынында аның нәтиҗәләре буенча акт төзү 248-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 1 өлешенең 6 – 9 пунктларында каралган контроль (күзәтү) гамәлләре кылуга бәйле рәвештә мөмкин булмаган очракта яки 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән башка очракларда, контрольдә тотучы орган актны контрольдә тотылучы затка 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Контроль (күзәтү) чарасын үткәрү нәтиҗәләре буенча акт, үзара хезмәттәшлек итмичә, мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта төзелә.

Контроль (күзәтү) чарасын үткәрү урынында акт төзү мөмкин булмаган очракта, мондый чара үткәрү тәмамланган көндә 248-ФЗ номерлы Федераль законның 87 статьясындагы 3 өлеше нигезендә актка кул куймаган контрольдә тотылучы зат, акт контроль (күзәтү) чараларының бердәм реестрында урнаштырылган һәм бу хакта 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешенең 2 пунктында каралган тәртиптә хәбәрнамә алынган очракта, актны алган дип санала.»;

6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Контроль (күзәтү) чарасын үткәргәндә контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта, контрольдә тотучы орган

Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

контроль (күзәтү) чарасының акты рәсмиләштерелгәннән соң контрольдә тотылучы затка, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү срокларын, шулай ук контроль төрләре турында федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирергә;

контроль (күзәтү) чарасын үткәргәндә контроль объектына ия булган һәм (яисә) аннан файдаланган граждан, оешмалар эшчәнлеге, аларның биналар, төзелмәләр, корылмалар, бүлмәләр, җиһазлар, транспорт чаралары һәм башка шундый объектлар эксплуатацияләве (алардан файдалануы), алар җитештерә һәм реализацияли торган товарлар, башкара торган эшләр, күрсәтә торган хезмәтләр закон белән сакланыла торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы турыдан-туры янаган яки мондый зыян (зарар) китерелгән очракта, кешеләр тормышы, сәламәтлеге өчен һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркыныч тудыра торган продукцияне (товарларны) мәҗбүри алу турында, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, бүлмәләрне, җиһазларны, транспорт чараларын һәм башка шундый объектларны эксплуатацияләүне (файдалануны) тыю турында һәм гражданнарга, оешмаларга теләсә нинди уңайлы ысул белән закон белән сакланыла торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы булу һәм аны булдырмау ысуллары турында мәгълүмат җиткерү турында таләп белән, хәтта судка мөрәҗәгать итүгә кадәр, закон белән сакланыла торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне булдырмау яки туктату буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кичекмәстән кабул итәргә;

контроль (күзәтү) чарасы барышында җинаять яки административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, тиешле мәгълүматны үз компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрергә яки тиешле вәкаләтләр булганда гаепле затларны закон белән билгеләнгән җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә;

ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, закон белән сакланыла торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү ихтималын булдырмау буенча чаралар күрергә, билгеләнгән сроклар эчендә күрсәтмә үтәлмәгәндә, әгәр мондый чара законнарда каралган булса, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән судка кадәр мөрәҗәгать итеп, аның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча тәкъдимнәр бирү, закон белән сакланыла торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү рискларын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар үткәрү турындагы мәсьәләне карап тикшерергә.»;

VII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «VII. Контрольдә тотучы органнарның карарларына, аларның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирү

7.1. Контрольдә тотучы органның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына), контрольдә тотучы орган тарафыннан төбәк дәүләт контролен (күзәтүен) үткәрү барышында кабул ителгән карарларга карата контрольдә тотылучы зат тарафыннан 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлеге нигезләмәләре буенча судка кадәрге тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Дәүләт серен яки закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән һәм документлардан гыйбарәт шикаятьләр контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы органга, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләре) бердәм порталын кулланмыйча, кәгазьдә дәүләт серен яки закон белән саклана торган башка серне саклауга бәйле мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актлар нигезләмәләрен үтәп тапшырыла.

Шикаятьне карап тикшергәндә контроль (күзәтү) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү буенча ярдәмче система (шикаятьне карау дәүләт серен яки закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклардан тыш) кулланыла.

7.2. Контрольдә тотучы органның вазыйфаи затлары карарларына, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять контрольдә тотучы органның җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан карап тикшерелә.

Контрольдә тотучы органның җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять контрольдә тотучы органның җитәкчесе тарафыннан карап тикшерелә.

7.3. Шикаять судка кадәр шикаять бирү буенча ярдәмче системада теркәлгән көненнән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш.

7.4. Шикаятьне карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карары, кабул ителгән көненнән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, контрольдә тотылучы затның дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталындагы һәм (яки) дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр төбәк порталындагы шәхси кабинетында урнаштырыла.

7.5. Шикаятьне карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру;

2) контрольдә тотучы органның карарын тулысынча яки өлешчә гамәлдән чыгару;

3) контрольдә тотучы органның карарын тулысынча гамәлдән чыгару һәм яңа карарын кабул итү;

4) контрольдә тотучы органның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип тану һәм дөрес итеп, кирәк булганда, билгеле гамәлләрне башкару турында карар чыгару.»;

8.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2025 ел – ≤13,6 процент;

2026 ел – ≤13,4 процент.»;

8.2 пунктта:

20 пунктчада «контроль (күзәтү) органы» сүзләрен «контрольдә тотучы орган» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктчада тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «контроль (күзәтү) органы» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «контрольдә тотучы орган» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктчада «контроль (күзәтү) органнарының» сүзләрен «контрольдә тотучы органнарның» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктчада «контроль (күзәтү) органнарының» сүзләрен «контрольдә тотучы органнарның» сүзләренә алмаштырырга;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Төбәк дәүләт контролен (күзәтүен) гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары исемлеге

9.1. Торак-төзелеш кооперативы («Торак төзелешен үстерүгә, туристлык инфраструктурасы объектларын булдыруга һәм территорияләрне башкача үстерүгә ярдәм күрсәтү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон белән төзелеше каралган торак-төзелеш кооперативларыннан тыш) тарафыннан өчтәк күбрәк катлы күпфатирлы йортны бердән артыграк төзүгә рөхсәт алу турында белешмәләр керү.

9.2. Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында контрольдә тотылучы зат тарафыннан урнаштырыла торган торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында хисап мәгълүматлары буенча шартнамәләрдә каралган, төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йорт составындагы торак урыннарны тапшыру срогын ике һәм аннан да күбрәк күчерү.

9.3. Россия Федерациясе Торак кодексының $123^{1}$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүмат өч һәм аннан күбрәк ай дәвамында актуальләштерелмәү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин